ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

21.06.2021　　　　с. Верхний Услон　　　　642

«Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2018нче елның 30нчы гыйнварындагы 102нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2010нчы елның 30нчы июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2018нче елның 30нчы гыйнварындагы 102нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (07.03.2018 ел, № 233, 06.05.2019 ел, № 418, 26.11.2019 ел, № 1195, 25.12.2019, № 1321, 24.01.2020, № 38, 30.04.2020, № 518, 03.07.2020, № 1095, № 1095 үзгәрешләр белән):

1.1. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген әлеге карарның кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә (1нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: https://verhniy-uslon.tatarstan.ruхалыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе　　　　　　　　И.И. Шакиров